

Торбеево муниципаль районында Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык конендә Рәшид һәм Равилә Коноваловлар, Заһид һәм Зинаида Вяльшиннар гаиләсе «алтын» туйларын билгеләп vттеләр.
Бу гаиләләрнен тормыш юлы ярты гасырдан артык дәвам итә. Бар кешегә дә мондый зур вакытны тынычлыкта һәм килешеп яшәргә насыйп булмый. Бер-берсен чор алмаштыра, әмма парлар бvгенге конгә кадәр бер-берсенә мәхәббәт, аерым жылылык һәм чын наз белән карыйлар. Патриотик принципларда vзләренен кече Ватаннары очен горурлык хисләре белән тәрбияләнгән бу буын кешеләре тирә-юньдәгеләрдә соклану һәм чиксез хормәт хисләре уята. Аларнын бәхетле гаилә монәсәбәтләренен нигезе булып, һичшиксез, тугрылык, сизгерлек һәм vзара анлашу тора.
Бу истәлекле конне юбилярларны котларга һәм тантаналы рәвештә ижтимагый бvләк – «Мәхәббәт һәм тугрылык очен» медален тапшырырга, Мордовия Республикасы Башлыгы Владимир Волковнын котлау адресын тапшырырга Торбеево муниципаль районы башлыгы урынбасары Николай Киреев, «Торбеево районы буенча халыкны социаль яклау» дәvләт казна учреждениесе житәкчесе Александр Пайганов белән ЗАГС бvлеге житәкчесе Наталья Еряшкина килгәннәр.



Якташларын олы бvләк белән Сыркыды авылы башлыгы Фәрит Тахир улы Эртуганов котлаган.
Шулай ук Ботенроссия Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык коне унаеннан vткәрелгән бәйрәмдә жиде парны Ләмберә ЗАГС бvлеге, район хакимияте хезмәткәрләре, vзешчән сәнгать артистлары, «Алмаз» мәдәни-кvнел ачу Yзәге тарафыннан бик жылы котлаганнар. Программаны алып баручы атказанган мәдәният хезмәткәре Гvзәл Казакова барлык кунаклар турында эчтәлекле чыгыш ясаган, жылы сvзләр ишеттергән. Берничә дистә ел бергә гомер иткән парларга карата бик кvп матур сvзләр әйткәннәр һәм изге теләкләр теләгәннәр. Мәсәлән, кырык ел бергә Равиль Жәфәр улы белән Роза

Мокаддәс кызы Кряковлар гомер итә. Рафаэль Жәфәр улынын Хәрби-дингез флотында хезмәт итv срогы 23 елны тәшкил итә. Һәм бу дәвердә хатыны анын белән командировка буенча Россиянен бер краеннан икенчесенә, иренен тугры юлдашы булып йоргән.



Пензятка авылыннан Камиль Абдрашит улы белән Равилә Өнвәр кызы Заликовлар гаиләсенә килгәндә, алар турында Омар Хайям сvзләре белән «Призыв» газетасында болай диелгән: «Бу кешеләрнен тормышы – китап. Анын титул битендә «мәхәббәт» сvзе язылган». Ирле-хатынлы Заликовлар законлы никахта инде 38 елдан артык яшиләр, әмма алар мәктәптә укыган вакытта танышканнар. Камиль Абдрашит улы - Афганистанда барган сугышчан хәрәкәтләрдә катнашкан. Ул авыл моселманнары жәмгыяте рәисе; зур ижтимагый эш алып бара. Равилә Өнвәр кызы vзенен ботен хезмәт эшчәнлеген Пензятка белән бәйләгән. Ул 25 ел авыл администрациясендә тырышып хезмәт иткән.
Район башлыгынын социаль мәсьә-ләләр буенча урынбасары Румия Хәким кызы Сәлимова юбилярларга бvләкләр белән «Мәхәббәт һәм тугрылык очен» медальләрен тапшырган.
Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык конен vткәрv буенча оештыру комитеты грамоталары белән Аладов һәм Кряков (фотодалар) гаиләләрен бvләкләгәннәр. Район башлыгынын Рәхмәт хаты белән дә берничә гаилә бvләкләнгән.
Озын гомерле гаиләләрдәге чиста мәхәббәтләре алга таба да аларга бетмәс-токәнмәс коч һәм оптимизм чыганагы булып хезмәт итсен, йортлары муллык белән тулсын, ә нәсел дәвамчылары һәрвакыт лаеклы терәк булсыннар.

**Н.Хәлил**